Татарстан Республикасы Конституциясен
гамәлгә кертү тәртибе турында

Татарстан Республикасы

З А К О Н Ы

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Татарстан Республикасының яңа Конституциясен, шушы Законның 5,6,7,8,9,10 статьяларында каралган кагыйдәләреннән тыш, игълан ителгән көненнән гамәлгә кертергә. Шул вакыттан Татарстан Республикасының 1978 елда кабул ителеп, соңыннан үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән Конституциясен гамәлдән чыккан дип санарга.

2 статья. Татарстан Республикасының яңа Конституциясенә каршы килмәгән Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты Указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, дәүләт органнарының башка актлары үз көчләрендә кала.

3 статья. Татарстан Республикасының яңа Конституциясен кабул иткәнче сайланган/билгеләнгән/ Татарстан Республикасы Президенты, Югары Советы, Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең башка органнары, шулай ук судьялар һәм прокурорлар чакырылыш /сайлану, билгеләнү/ чорлары тәмамланганчы, Татарстан Республикасының яңа Конституциясе тапшырган барлык вәкаләтләрне башкаралар дип санарга.

4 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт /парламент/ контроль комитеты, Конституциядә билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Югары Советының Парламент контроль комитетын сайлаганчыга кадәр эшли.

5 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең

7I статьясындагы: Татарстан Республикасы халык депутаты бүтән Советның депутаты була алмый, дигән кагыйдәсен Татарстан Республикасының яңа чакырылыш Югары Советы оешканнан соң гамәлгә кертергә.

6 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару җыены хакындагы статьяларындагы кагыйдәләр Закон чыгару җыены турында закон кабул иткәннән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә тиешле үзгәрешләр керткәннән соң гамәлгә керә.

7 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Югары Советы секретаре турындагы статьялары кагыйдәләрен Татарстан Республикасының яңа чакырылыш Югары Советы оешканнан соң гамәлгә кертергә.

8 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Конституция суды турындагы I40 статьясы кагыйдәсен Татарстан Республикасының Конституция судын сайлаганнан соң гамәлгә кертергә.

9 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең 72 статьясындагы: җирле администрация башлыгы урынбасарлары һәм администрациянең структура бүлекләре җитәкчеләре шушы җирле Советның депутаты була алмый, диелгән кагыйдәсен яңа чакырылыш җирле Советлары оешканнан соң гамәлгә кертергә.

I0 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты турындагы статьялары кагыйдәләрен Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты турындагы законы кабул ителгәннән соң гамәлгә кертергә.

II статья. Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителүен исәпкә алып, Россия Федерациясе - Россия Югары

Советына Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе - Россия арасындагы мөнәсәбәтләрнең конституциячел килешүгә нигезләнгәнлеге турындагы кагыйдәләрне Россия Федерациясенең Төп Законында беркетү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә.

I2 статья. Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумына Татарстан Республикасында закон чыгару эшен оештыру һәм Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасының яңа Конституциясенә туры китерү тәртибен билгеләргә.

I3 статья. Бу Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев